**Республика Татарстан**
**Сармановский муниципальный район**
**Карашай Сакловское сельское поселение**
**423378 ул.Ленина д.100 с.Карашай Саклово Телефон: 885559 4-92-18**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай Саклау авыл жирлеге**
**423378, Карашай Саклау авылы, Ленин ур.100 йорты Телефон: 885559 4-92-18**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 ноябрь 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Карашай-Саклау авылында гражданнарның 2026 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Уставы:

1.Карашай-Саклау авылы мәдәният йорты бинасында, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 19 нояберенә 9 сәгать 00 минутта билгеләргә

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга: «I группа инвалидлар, көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2026 елда 600 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

1. 1. Аларга якын территориядәге коеларны төзү, ремонтлау:

-Карашай-Саклау т. п. Гагарин урамындагы коены ремонтлау, материаллар сатып алу;

2. Торак пунктлар территорияләрен төзекләндерү:

- Беларусь МТЗ 82.1 тракторының ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, йөртүче хезмәтләре өчен түләү)

- Карашай-Саклау торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- вак таш түшәмәне ремонтлау (махсус техниканы арендалау, эшләрне һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләрне түләү, вак ташу һәм салу, Су Буе урамында грейдерлау)

4. Көнкүреш калдыклары, чүп-чар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру һәм чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү, махсус аренда.Карашай-Саклау т. п.;

5. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- янгын сүндерү емкосы өчен авторезина һәм мотопомпа сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК?».

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Чураш авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Карашай-Саклау
авыл җирлеге Башлыгы В. В. Хөсниева